| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУГУНУРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ КУНЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» март 2026 ел № 24

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советының 26.07.2024 № 100 карары белән расланган Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 567-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Балтач районы прокуратурасының 12.03.2026 №02-08-01-2026/Прдп86-26-209011 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль турында» 2024 елның 29 июлендәге 103 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге советы карары белән расланган Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендәге муниципаль контроль хакындагы Нигезләмәгә (27.11.2024 ел №116, 25.06.2025 ел № 131 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) контрольдә тотыла торган зат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган критерийларга туры килми.»;

1.2. 3.5.6 пунктта «контроль (күзәтчелек) чаралары,» сүзләрен «мәҗбүри профилактик визитлар,» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Мәҗбүри профилактик визитны үткәрү турында контрольдә тотыла торган зат «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә ул башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр итә.

1.4. 3.5.1 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (региональ дәүләт контроле (күзәтчелек), федераль дәүләт контроле (күзәтчелек) төрләренә карата, аларны гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектлары дәүләт

хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелек) төрләренә һәм әлеге Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда муниципаль контроль төрләренә карата).»;

1.5. 3.5.1 пунктының 2 пунктчасында «муниципаль контроль» Исемлек.» сүзләрен «муниципаль контроль», яисә белешмәләре урнаштыру чараларының классификацияләнгән реестрына кертелгән контроль астындагы затлар. Исемлек» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы — Р.О. Егоров